**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 23 гыйнварындагы 116 номерлы карары**

# Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә 2025 елга өстәмә социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында

Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 28 декабрендәге 3492 номерлы карары белән расланган «2022-2026 елларга Казан шәһәрендә мәгарифне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында һәм мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү, шулай ук Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә хезмәт күрсәтүче кече персоналны саклап калу максатыннан, **карар бирәм**:

1. 2025 елга мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган түбәндәге категория гражданнарга балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешен өстәмә компенсацияләүне билгеләргә:

- беренче һәм икенче дәрәҗәдәге уку-укыту һәм ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә, шулай ук «Беренче һәм икенче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркемнәренә кертелгән муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре булып эшләүче ата-аналарга;
- I һәм II төркем инвалид ата-аналарга;

- мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче баланың ата-анасы булган I һәм II төркем инвалидка – иренә (хатынына).

2. 2025 елга мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешен өстәмә компенсацияләү тәртибен (алга таба – Тәртип) әлеге карар кушымтасы нигезендә расларга.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсен мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешен өстәмә компенсацияләүне түләү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсенә (И.А.Ризванов):

4.1. мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешен өстәмә компенсацияләүне расланган Тәртип нигезендә тормышка ашырырга;

4.2. законнар нигезендә консультатив хезмәтләр күрсәтү, документларны җыю һәм кабул итү, ата-ана түләвенең бер өлешен өстәмә компенсацияләүне исәпләү һәм билгеләү буенча чараларны мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарны кабул итү, консультацияләү, өстәмә

компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү хезмәтләрен күрсәтүгә килешү төзелгән махсуслаштырылган оешма аша башкарырга;

4.3. мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешен өстәмә компенсация буларак түләү чыгымнарын Казан шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең бюджет исемлегендә «2022-2026 елларга Казан шәһәрендә мәгарифне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру өчен 2025 елга каралган акчалар кысаларында «Халыкны социаль тәэмин итү» дигән 1003 бүлеге буенча башкарырга;

4.4. мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарны кабул итү, консультацияләү, өстәмә компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул итү буенча хезмәтләр күрсәтүгә килешү төзелгән махсуслаштырылган оешма хезмәтләрен түләү буенча чыгымнарны «Мәгариф өлкәсендәге башка мәсьәләләр» дигән 0709 бүлеге буенча башкарырга.

5. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

7. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 29 декабрендәге 4429 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә 2024 елга өстәмә социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 23 гыйнварындагы
116 номерлы карарына
кушымта

**2025 елга мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешен өстәмә компенсацияләү тәртибе**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге тәртип 2025 елга мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешен өстәмә компенсацияләүне билгеләү һәм түләү механизмын билгели.

1.2. Балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә ата-ана түләвенең бер өлешен өстәмә компенсацияләү тәртибе мәктәпкәчә һәм кече мәктәп яшендәге балалар өчен белем бирү оешмаларына (башлангыч мәктәп – балалар бакчасы, прогимназия) кагыла.

1.3. Компенсация мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы карау һәм тәрбияләү өчен

ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында»гы карары һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 декабрендәге 5257 номерлы «2025 елга мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында»гы карары белән каралган ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация алучы түбәндәге гражданнар категориясенә билгеләнә һәм түләнә:

- беренче һәм икенче дәрәҗәдәге уку-укыту һәм ярдәмче персонал хезмәткәрләре вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәренә, шулай ук «Беренче һәм икенче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркемнәренә кертелгән муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре булып эшләүче ата-аналарга;
- I һәм II төркем инвалид ата-аналарга;
- мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче баланың ата-анасы булган I һәм II төркем инвалидка – иренә (хатынына).

1.4. Компенсация әлеге тәртипнең 1.3 пунктында күрсәтелгән гражданнарның аерым категорияләре саныннан булган, муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе белән килешү төзегән һәм мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган тиешле мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвен керткән законлы вәкилгә (ата-анага, тәрбиягә алучыга, опекунга) (алга таба – гариза бирүче) билгеләнә һәм түләнә.

1.5. Компенсация күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

К3= Ф – К1 – К2, монда:

К3 – гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә компенсация күләме;

Ф – Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 28 октябрендәге 4553 номерлы карары белән расланган ата-ана түләвенең күләме чикләрендә мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә баланы карау һәм тәрбияләү өчен түләнелгән ата-ана түләвенең күләме;

К1 – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 18 гыйнварындагы 9 номерлы «Мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмаларында баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү турында»гы карары белән билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган мәктәпкәчә белем бирү

учреждениеләрендә баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү күләме;

К2 – Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 декабрендәге 5257 номерлы «2025 елга мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында»гы карары белән билгеләнгән тәртиптә исәпләнгән мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә баланы карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешен компенсацияләү күләме.

## II. Компенсация билгеләү һәм түләү тәртибе

2.1. Компенсация алу өчен гариза бирүче мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарны кабул итү, аларга консультация бирү, өстәмә компенсация билгеләү турында (билгеләүне кире кагу турында) карар кабул итү хезмәтләре күрсәтүгә вәкаләтле орган белән гражданлык-хокукый килешү төзелгән махсуслаштырылган оешмага Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча (гариза бирүче яшәү урыны буенча теркәлмәгән очракта – тору урыны буенча), ә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлмәгән гражданнар өчен – тиешле белем бирү оешмасын теркәү урыны буенча түбәндәге документларны тапшыра:

- компенсация билгеләү турында гариза;
- әлеге тәртип кушымтасы нигезендә расланган форма буенча бирелгән ата-ана түләвенең бер өлешен өстәмә компенсацияләүне алу хокукы турында эш урыныннан белешмә (муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре өчен);
- инвалидлык билгеләүне раслый торган документлар (I һәм II төркем инвалид ата-аналар өчен);
- өйләнешү турында таныклык (мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә йөрүче баланың ата-анасы булган I һәм II төркем инвалид ир (хатын) өчен).

Мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан

шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарны кабул итү, консультацияләү, өстәмә компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү хезмәтләре күрсәтүгә вәкаләтле орган белән гражданлык-хокукый килешү төзелгән махсуслаштырылган оешмада компенсация бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматлар булган очракта, гариза бирүче югарыда күрсәтелгән документларның барысын да яки бер өлешен бирү бурычыннан азат ителә.

Гариза бирүче гариза белән мөрәҗәгать иткәндә паспортын (аны алмаштыра торган документ), компенсацияне банк аша алганда мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе белән килешү төзегән затның кредит оешмасындагы шәхси счет номерын күрсәтә.

2.2. Гариза һәм документлар почта аша җибәрелергә мөмкин. Гаризаны һәм документларны почта аша җибәрү махсуслаштырылган оешма тарафыннан аларны алу фактын һәм көнен расларга мөмкинлек бирә торган ысул ярдәмендә башкарыла.

2.3. Вәкаләтле орган ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның 2 сенә кадәр, мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарны кабул итү, консультацияләү, өстәмә компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү хезмәтләре күрсәтүгә гражданлык-хокукый килешү төзелгән махсуслаштырылган оешмага электрон рәвештә компенсация бирү өлешендә махсуслаштырылган оешманың вәкаләтле орган белән үзара мәгълүмати хезмәттәшлеге турындагы килешүдә билгеләнгән таләпләр нигезендә мәгълүмат бирә.

2.4. Әлеге тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документлар һәм тапшырылган муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләре исемлеге нигезендә, мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарны кабул итү, консультацияләү, өстәмә

компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү хезмәтләре күрсәтүгә гражданлык-хокукый килешү төзелгән махсуслаштырылган оешма барлык кирәкле документлар белән гариза теркәлгән көннән алып 10 көн эчендә компенсация билгеләү яки билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм тиешле карарны гариза бирүчегә гариза бирүче күрсәткән ысул (хат, СМС-хәбәр, электрон почта; ә Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының теркәлгән файдаланучылары булып торучы гариза бирүчеләргә – шәхси кабинет аша белдерү хаты белән) ярдәмендә җиткерә.

2.5. Компенсацияне билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

- әлеге тәртипнең 2.1 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау;
- гамәлдә булу вакыты узган документлар тапшыру (күрсәтү);
- закон таләпләрен бозып рәсмиләштерелгән документлар тапшыру;
- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычы булу.

2.6. Түбәндәге очраклар компенсация түләүне туктату өчен нигез булып тора:

- ата-ана түләвенең бер өлешен өстәмә компенсацияләүне алу хокукын югалту (эш мөнәсәбәтләрен туктату, башка вазифага күчү, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 декабрендәге 5257 номерлы карары нигезендә компенсация алу хокукы булмау);
- белем бирү оешмасын алыштыру;
- ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү;
- гариза бирүченең үлеме.

## III. Йомгаклау нигезләмәләре

3.1. Гариза бирүче тапшырылган мәгълүматларның дөреслеге, шулай ук аларны үз эченә алган документларның чын булуы өчен җаваплы.

3.2. Вәкаләтле орган өстәмә компенсация бирү хокукына белешмәләрдә күрсәтелгән мәгълүматларның һәм әлеге тәртипнең 2.3 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеге өчен җаваплы.

3.3. Мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге

муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарны кабул итү, консультацияләү, өстәмә компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү хезмәтләре күрсәтүгә вәкаләтле орган белән гражданлык-хокукый килешү төзелгән махсуслаштырылган оешманың, тапшырылган документларның һәм мәгълүматларның дөреслеккә туры килүе шик тудырган очракта, бирелгән вәкаләтләр кысаларында гариза бирүче тапшырган мәгълүматларны өстәмә тикшерергә хокукы бар.

3.4. Компенсация суммасы гариза бирүченең банк счетына күчерелә.

Сәламәтлеге, яше, җәяү яки транспорт белән барып банкта счет ачу һәм аннан файдалану мөмкинлеге булмаган гариза бирүчегә компенсация түләү (китерү) элемтә оешмалары аша яисә гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле килешүләр (контрактлар) төзелгән акчалата түләүләрне китерү белән шөгыльләнә торган башка оешмалар аша гамәлгә ашырыла.

3.5. Компенсацияне банк счетларына күчерү һәм аны почта элемтәсе яисә гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә тиешле килешүләр (контрактлар) төзелгән акчалата түләүләрне китерү белән шөгыльләнә торган башка оешмалар аша хисап ае дәвамында башкарыла.

3.6. Гражданнар мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарны кабул итү, консультацияләү, өстәмә компенсация билгеләү турында (билгеләүне кире кагу турында) карар кабул итү хезмәтләре күрсәтүгә вәкаләтле орган белән гражданлык-хокукый килешү төзелгән махсуслаштырылган оешмага компенсация түләүне туктатуга китерә торган шартлар барлыкка килүе турында әлеге шартлар барлыкка килгән вакыттан алып бер айдан да соңга калмыйча хәбәр итәргә тиеш.

3.7. Түләүне туктатуга китерә торган шартлар барлыкка килгәндә, түләү тиешле шартлар барлыкка килгән айдан соң килә торган айдан туктатыла.

3.8. Өстәмә компенсация алу хокукына йогынты ясый торган күрәләтә дөрес булмаган мәгълүматлар язылган документлар тапшыру һәм мәгълүматларны яшерү нәтиҗәсендә артык түләнгән компенсация суммалары вәкаләтле органның казна счетына гариза бирүче тарафыннан ирекле рәвештә түләнелә, ә гариза бирүче баш тарткан очракта – Россия Федерациясе законнары нигезендә түләттерелә.

3.9. Вәкаләтле орган гаебе белән вакытында алынмаган компенсация үткән

вакыт өчен чикләнмәгән срокта түләнә.

3.10. Гариза бирүче вафат булган очракта, аңа исән чакта түләнмәгән компенсация суммасы мирас составына кертелә һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән гомуми нигезләрдә мирас итеп алына.

3.11. Компенсация бирү мәсьәләләре буенча бәхәсләр суд тәртибендә хәл ителә.

2025 елга мәктәпкәчә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыра торган Казан шәһәренең муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә, Казан шәһәренең гомуми белем бирү учреждениеләрендәге мәктәпкәчә төркемнәргә, шулай ук Казан шәһәренең хосусый белем бирү учреждениеләрендәге муниципаль төркемнәргә йөрүче балалары булган гражданнарның аерым категорияләренә балаларны карау һәм тәрбияләү өчен ата-ана түләвенең бер өлешен өстәмә компенсацияләү тәртибенә кушымта (Форма)

**Ата-ана түләвенең бер өлешенә**
**өстәмә компенсация алу хокукы турында**
**белешмә**

Бирелде______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

ул чыннан да __________________ датадан (эшкә кабул итү датасы) ________________________________________________________________________
(муниципаль учреждениенең атамасы)

Казан шәһәре Башкарма комитетының ________________________ ___________________________________карары белән расланган тәртип нигезендә
(норматив-хокукый акт атамасы)

ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация алу хокукы бирә торган ________________________________________________________________________
(вазифа атамасы)

вазифада эшли.

Белешмә тиешле урынга тапшыру өчен бирелә.

Учреждение җитәкчесе ________________/_________/
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имза)

2025 елның «____»___________

Мөһер урыны